АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.01.2019 ел

2019 елга Актанышбаш авыл җирлеге территориясендә хатын-кызлар советы составына үзгәрешләр кертү һәм эш планын раслау турында

Хокук саклау органнарына һәм башка дәүләт органнарына хокук тәртибен тәэмин итүдә ярдәм күрсәтү, социаль әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә киң җәмәгатьчелекне җәлеп итү, хатын-кызларның, гаиләнең, аналарны һәм балаларны саклауның торышын яхшырту һәм хатын-кызларның җәмәгать эшләрендә актив катнашуы өчен уңай шартлар тудыру максатларында,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Кадрлар алышыну сәбәпле, Актаныш муниципаль районының Актанышбаш авыл җирлеге территориясендә хатын-кызлар советының яңа составын расларга (1 нче кушымта).

2. Расларга:

2.1. 2019 елга Актаныш муниципаль районының Актанышбаш авыл җирлеге территориясендә хатын-кызлар советы чаралары планы (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Актанышбаш авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatar.ru/rus/aktanysh/poselenia.htm.урнаштырырга.

4, Әлеге карар рәсми игълан ителгән вакыттан үз көченә керә.

5. Актанышбаш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 10.01.2017 елгы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

б. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Актанышбаш башкарма комитеты җитәкчесе Л.Г.Хайдарова

Актанышбаш Башкарма комитеты
җитәкчесе карарына ________ №____
кушымта

Актанышбаш авыл җирлеге территориясендә хатын-кызлар советы составы

| | |
|---|---|
| Имамова Гөлназ Ринат кызы | хатын-кызлар советы рәисе, Әҗәкүл балалар бакчасы мөдире (килешү буенча) |
| Хәкимова Дилара Хатип кызы | «Актанышбаш мәдәният йорты» МБУ, рәис урынбасары, китапханәче (килешү буенча) |
| Солтанова Лозия Рәхимҗан кызы | хатын-кызлар советы секретаре, Чөгәнә мәктәбендә укытучы (килешү буенча) |

Хатын-кызлар советы әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Лотфрахманова Гөлшат Нуретдин кызы | ФАП фельдшеры (килешү буенча) |
| Арсланова Алсу Илфар кызы | Чөгәнә клубы методисты (килешү буенча) |
| Әдиятуллина Марсельеза Ямалетдин кызы | Әҗәкүл башлангыч мәктәбе укытучысы (килешү буенча) |

Актаныш авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 19.OI.2019 елгы карарына
2 нче кушымта

2019 елга Актанышбаш авыл җирлегенең хатын-кызлар Советы эшчәнлеге

| | Чаралар | Үткәрү датасы | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1. | Җирлек советы хатын-кызлары утырышын үткәрү һәм 2019 елга эш планын раслау | квартал саен | Совет рәисе,<br><br>Совет әгъзалары |
| 4. | Чараларны үткәрүдә катнашу:<br>- республика көне<br>- халыкара хатын-кызлар көне<br>- гаилә көне<br>- балаларны яклау көне<br>- өлкән яшьтәге кешеләр көне<br>- авыл җирлекләре арасында спартакиадалар - әниләр көне<br>- 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 73-еллыгын бәйрәм итү «Яле, кызлар, әниләр һәм әбиләр!»<br>- үзешчән сәнгать смотры<br>- "Иң яхшы бакча алды - 2019" конкурсы | ел дәвамында | Совет рәисе,<br><br>Совет әгъзалары |
| 5. | «Хатын-кызлар эшчәнлеге» папкасын һәм стендын бизәү | Ел дәвамында | Совет рәисе,совет әгъзалары |
| 6. | Хатын-кызлар советы эшчәнлегенә анализ ясарга, аны камилләштерүгә юнәлтелгән тәкъдимнәр эшләү нәтиҗәләре буенча | Ел дәвамында | Совет рәисе<br><br>Совет әгъзалары |
| 7. | Эчке эшләр министрлыгының участок уполномоченныйлары һәм инспекторлары белән хезмәттәшлектә социаль имин булмау сәбәпләрен ачыклау максатында яшәү урыны буенча булу:<br>- алкоголь белән кирәгеннән артык файдаланучы гаиләләрдә;<br>- балигъ булмаган хокук бозучыларда; | Ел дәвамында | Совет рәисе<br><br>совет әгъзалары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8. | Җәмгыятьнең аерым игътибарына мохтаҗ хатын-кызларны исәпкә алу (күпбалалы, ялгыз аналар, ялгыз һәм яшьтәгеләр, эчүчеләр һ.б. | Ел дәвамында | Совет рәисе<br>совет әгъзалары |
| 9, | Мәгълүмат-белешмә, методик материаллар әзерләү | Ел дәвамында | Совет рәисе<br>Совет әгъзалары |
| 10. | Беренче сыйныфка баручы балаларның әниләре белән очрашуны оештыру: « Беренче сыйныф укучысының адаптациясендә гаиләнең роле» | Август | Җирлек мәктәпләре укытучылары |
| 11. | Сәламәтлек саклау органнары белән берлектә имин булмауның иртә стадиясендә торган гаиләләрне һәм балигъ булмаганнарны ачыклау, гражданнар белән индивидуаль профилактик эш алып бару | Ел дәвамында | Совет рәисе<br>Совет әгъзалары |
| 12. | ОВД һәм җирлек җәмәгатьчелеге советы белән үзара хезмәттәшлектә законсыз алкоголь сату урыннарын ачыклау һәм нейтральләштерү, ялган алкоголь продукция җитештерү буенча рейдлар үткәрергә | Ел дәвамында | Совет рәисе<br>Совега әгъзалары |
| 13. | Җирлек җәмәгатьчелеге Советы белән берлектә яшьләрнең күпләп җыела торган урыннарына исереклекне, наркоманияне һәм тәмәке тартуны кисәтү максатыннан рейдлар үткәрергә. | Ел дәвамында | Совет рәисе<br>Совет әгъзалары |
| 14, | Массакүләм чараларда, дежурлыкта катнашырга | Ел дәвамында | Совет рәисе, совет әгъзалары |